| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ШӘЙМОРЗА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Иске Шәйморза

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№24/1 2023 ел 30 нче январе

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 апрелендәге 32/1 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен, даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр билгеләү турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары, Чүпрәле муниципаль районының Иске Шәйморза авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 апрелендәге 32/1 номерлы (2018 елның 25

маендагы 33/1; 2018 елның 11 сентябрендәге 37/2; 2018 елның 11 ноябрендәге 44/2; 2019 елның 14 февралендәге 45/2; 2020 елның 13 ноябрендәге 3/4; 2022 елның 3 октябрендәге 21/4 номерлы карарлары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен, даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр билгеләү турында » гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) “Авыл җирлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт хакы күләме һәм шартлары”** 1 нче кушымта таблицасын

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 группа | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| “Авыл җирлеге башлыгы | - | - | - | 15759 |

**түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:**

| Вазыйфаның атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 группа | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| Авыл җирлеге башлыгы | - | - | - | 17390»; |

**1 кушымтадагы** «Авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата бүләкләүдән тыш, елына 6,72 айлык акчалата бүләк күләменнән артмаган, айлык акчалата бүләк түләнә.» дигән абзацны **киләсе редакциядә бәян итәргә:**

“Авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата бүләкләүдән тыш, елына 9,26 айлык акчалата бүләк күләменнән артмаган, айлык акчалата бүләк түләнә”.

**2) “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфаи окладлы күләме "**
2 нче кушымта таблицасын:

| | Вазыйфаның атамасы | Вазифалы оклад | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| 2. | Башкарма комитет сәркатибе | - | - | 15292 |

түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

| | Вазыйфаның атамасы | Вазифалы оклад | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| 2. | Башкарма комитет сәркатибе | - | - | 16875”. |

3) **"Авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләүне түләү күләме һәм тәртибе”** турындагы **6 кушымтада** «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы
Чүпрәле муниципаль районы
Татарстан Республикасы                                        И.Д.Мөхитова